ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**

**НОЯБРЬ, 2015 нче ел**

**№3 (20)**






**Ноябрьдә иң кадерле кешеләребезне котларга онытмыйк!**

✓ **29**– Әниләр көне

## Мин һәм минем хокукларым

Кеше хокукларын, аеруча бала хокукларын яклау дәүләтнең иң мөһим бурычларының берсе булып тора. 20 ноябрь – Балаларның хокукларын яклау көне. Бу көн 145 илдә билгеләп үтелә. Һәм аның 20 ноябрьгә билгеләнүе очраклы түгел. Нәкъ шушы көндә 1959 елда бала хокуклары декларациясе, ә 1989 елда бала хокуклары турында Конвенция кабул ителә. Бу көнне барлык илләрдә балалар хокукларын яклауны искәрткән чаралар оештырыла. Нәкъ 20 нче ноябрь көнне мәктәбебездә тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Фахреева Г.Я. уртанчы сыйныф укучылары белән “Минем хокукларым” дигән темага сыйныфтан тыш чара үткәрде. Укучыларга үзләренең хокуклары турында мәгълүмат житкерелде, аларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирелде.

**Гөлшат Гайсина**

## Бу санда:

| | |
|---|---|
| Кыш Бабайның туган көне | 2 |
| Якыннан танышыйк! | 3 |
| Грипптан саклан! | 4 |
| Иң көчлеләр билгеле | 4 |
| Көлке хикмәте | 4 |
| Иң– иңнәребез! | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |

**Һәр бала туганнан алып исемгә һәм гражданлык алуга хокуклы.**
**Тормышына куркыныч янамаса, бала әти-әнисеннән аерылырга тиеш түгел.**
**Түләүсез белем алуга хокуклы.**
**Дәүләт әти-әнисез калган бала турында кайгыртырга тиеш.**




**Беркем һәм беркайчан да баланы газапларга һәм хурларга тиеш түгел.**

**Балалар сәламәтлек саклау системасында иң яхшы чаралардан файдалануга хокуклы**
**Балалар ялга һәм уенга, өлкәннәр белән беррәттән ижат эшчәнлегендә катнашырга хокуклы.**

## Отборочный тур республиканского конкурса ОО, развивающих ученическое самоуправление

**24 ноября** на базе МБУ ДО «ЦДТ» прошел отборочный тур республиканского конкурса общеобразовательных организаций, развивающих ученическое самоуправление. Члены ШУС нашей школы выступили с визитной карточкой. Для оценки работ на сайте школы была выложена презентация о деятельности ШУС, а также был приготовлен пакет документов согласно положению.

**Хайбуллина Алсу**



## Безгә кунаклар килде

**25 нче ноябрь** көнне мәктәбебездә районның рус теле һәм әдәбияты укытучыларының семинары үтте. Катнашучылар 9 нчы сыйныфта дәресләрдә дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлеккә багышланган дәрес караса, 5 сыйныфта исә бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә багышланды. Бишенчеләр ФДББС нигезендә хат язу серләренә өйрәнделәр. Бүгенге көндә кулланылыштан чыгып бара торган аралашу чарасы укучыларда зур кызыксыну уятты, кунаклар да зур тәэсирләнү алдылар. Дәрес ахырында укучылар язып өлгергән хатларны тыңлау исә беркемне дә битараф калдырмады. Клара Касымовна Ситдикова һәм Гөлүсә Дамировна Әһлиуллина җитәкчелегендә оештырылган Әниләр бәеклегенә багышланган сыйныфтан тыш чара барысын да елмайтты да, елатты да.

**Рәзилә Абдрахманова**







## 18 нче ноябрь - Кыш Бабайның туган көне



Һәркемнең дә туган көне булган кебек, Кыш бабайның да туган көне бар икән, ләбаса. Ничә яшь икәнен төгәл белмәсәк тә, бүген ул бәйрәмен билгеләп үтә, диделәр. Кыш бабай дигәч, сездә нинди тәэсирләр уяна, туган көне уңаеннан аңа нинди теләкләрегез бар? Сораштыруыбыз шул хакта.

**Зәринә Хисматова, 4 сыйныф :**
-Кыш бабай дигәч, ап-ак кар өстеннән капчыгын асып, таягына таянып, шат елмаеп баручы Кыш бабай күз алдыма килә. Аның турында сөйләшә башлауга ук күңелне шатлык хисе били башлый. Ул килер алдыннан нindидер могҗиза көтәсең, ул киткәч тә ниндидер үзгәрешләр булыр кебек тоела.

**Флүсә Гомәрова, укытучы:**

- Кыш бабай дигәч, төрле костюмнар киеп чыршы әйләнәсендә чабышып йөргән, чын Кыш бабай дип ышанып, каушый-каушый шигырьләр сөйләгән, куанып бәйрәм пакетлары күтәреп кайткан балалар күз алдына килә. Яңа дигән сүзгә бәйле рәвештә яңа тормыш башланыр, авырлыклар артта калыр дигән өмет, ышаныч уяна. Ә теләгемә килгәндә, көтелмәгән шатлык-куанычлар безгә дә һәрвакыт очрап торсын, Кыш бабай –карт бабай булса да гел шундый актив, яшь күңелле булып калсын. **Яшәсен Кыш бабай!**

**Юнусова Виктория**

## Якыннан танышыйк!





Раилә Заһитовна, ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз?

- Мәктәптә укыганда, математика укытучысы Исламия апаның дәресләрен ярата идем, һәм ул укытучы һөнәрен сайлавымда зур этәргеч булды.

- Мәктәптә укыган вакытта Сезнен яраткан фәннәрегез?

- Әйтеп үткәнемчә, математика укытучылары Биккол мәктәбендә—Исламия Минехановна, Фомада - Роза Вәлиәхмәтовна, тарих укытучысы Фәнил Вәгыйзович, рус теле һәм әдәбияты укытучысы һәм сыйныф җитәкчебез Салих Шакирович яраткан укытучыларым һәм остазларым булдылар.

- Сезнең хоббиегыз нинди?

- Мин пешерергә яратам, бигрәк тә камыр ризыклары. Эштән бик каты арып кайтсам да, гаиләмне өчпочмак, гөбәдия, вак бәлеш кебек татар халык ашлары белән сыйларга вакытын да, җаен да табарга тырышам.

**Хәзерге укучыларга һәм укытучыларга нәрсәләр теләр идегез?**

– Коллегаларыма – лаеклы хезмәт хакы, сабырлык, укучыларны ярату, ә балаларга лаеклы кешеләр булып үсүләрен, Ватаннарын – Россия Федерациясен һәм Татарстанны ярауларын теләр идем. Киләчәк алар кулында. Һәр яшь кешегә, ошаган һөнәрен сайлап, тормышыннан тәм һәм ямь табып яшәргә язсын иде. Халыкта: “Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау бәхетне төшендә күрер” дигән мәкаль бар бит. Халык әйтсә, хак әйтә.

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**



## Ял файдалы узды



Мәктәптә көзге каникул вакытында (2.11.15-9.11.15) **"Спорт—экспресс"** программасы буенча көзге лагерь эшләде. Укучылар үзләренең вакытларын бик күңелле уздырдылар: төрле спорт уеннарында, конкурс, викториналарда катнаштылар, үзләренең белемнәрен арттыру өстендә эш алып бардылар.



## ГРИППТАН САКЛАН!

Грипп – сулыш юлларын ялкынсындыручы инфекцион авыру. Авыру барышында томау, тамак ялкынсыну, ютәлләү, тамак төбе авырту күзәтелә. Куркыныч грипп вирусының организмны агулап, төрле әгъзалар эшчәнлегенә зарар китерүе бик мөмкин. Авыру вакытында югары тән температурасы, баш авырту, тән сызлау, костыру, галлюцинацияләр дә булуы ихтимал.

***Гайшә Таһирова***

**Тирләтүче чәй эчегез.** Берәр аш кашыгы бал, гөлҗимеш, карлыган, кура җиләген алып 200 мл кайнар суда 15 минут төнәтегез һәм ашар алдыннан көненә өч тапкыр яртышар стакан эчегез. Шуннан соң юрганга төренеп ятыгыз.



# Көзге боз өсте: сак булыгыз, хәтәр!

Елгаларда су 10 сантиметр калынлыкта катса гына кеше өчен куркыныч булмый. Елга тамакларында, камышлыкларда боз юкарак була. Әгәр һава температурасы өч көн дәвамында 0 градустан югарырак тора икән, бозның калынлыгы 25 процентка кими. Бозның калынлыгын гади күз белән дә билгеләп була: зәңгәрсу төстәге боз – ныклы, ак төстәгесе юкарак, соры яисә саргылт булса, ышанычсыз.

Әгәр дә боз өстендә бәла-каза чыкса, паникага бирелмәскә, кискен хәрәкәтләр ясамаска кирәк. Әгәр дә, боз ярылып, салкын суга батсагыз, нишләргә?


Бу очракта кулларны җәеп, ничек тә булса, бозга башта бер аякны, аннан соң икенчесен күтәреп, шуышып, менәргә кирәк. Әгәр дә боз сезнең авырлыкка чыдаса, әкрен генә ярга таба үрмәләргә була. Кайсы ярдан килгәнсез, шул якка үрмәләргә кирәк, чөнки анда боз тикшерелгән.

Әгәр дә Сезнең ярдәм таләп ителсә, нишләргә?

Озын таяк, такта, яисә бау табарга. Йә булмаса шарф, каеш һәм киемнәрне бергә бәйләргә була.

Бозга ятып, шушы әйберләр белән бәлагә таручы ягына шуыша башлагыз. Суга батучы янына җитәргә бер-ике метр калгач, туктарга һәм таякны, тактаны яисә бауны кирәк кадәр. сузып, бәлагә таручыны куркыныч зонадан чыгарырга тырышыгыз. Зыян күрүчене коткаргач, җылы урын табып, аның юеш киемнәрен салдырырга, тәнен спирт яисә аракы белән ышкырга, кайнар чәй эчерергә кирәк. Әмма беркайчан да суга батучыга эчәргә аракы бирмәгез. Ул аны үлемгә китерергә мөмкин.

**Россия МЧСының Татарстан Республикасындагы ГИМС үзәге.**



ВНИМАНИЕ ! В ТАКИХ МЕСТАХ ПОД СНЕГОМ МОГУТ БЫТЬ ГЛУБОКИЕ ТРЕЩИНЫ И РАЗЛОМЫ.

*Аллаһыбыз:*
*«Саклангнанны саклармын!» - дигән.*

# Алар олимпиадаларда мәктәп данын яклаячак

**Октябрь ае буена укучылар төрле фәннәр буенча илкүләм олимпиадаларның мәктәп турында көчләрен сынады. Инде мәктәп данын район турында яклау хокукын алучылар исемлеге билгеле булды.** Болар: инглиз теленнән Гомәрова Ләйсән, Шакурова Алсу, Шарапова Ләйсән, математикадан Закирова Гөлинә, Аглетдинова Гөлләр, Гомәров Ранис, Әһлиуллин Аяз, Сафиуллин Хәлил, биологиядән Әһлиуллин Аяз, Вәгыйзова Ләйсән, тарихтан Әһлиуллин Аяз, Сөләйманова Айсылу, рәсем сәнгатеннән Юнусова Виктория, тормыш иминлеге нигезләреннән Зиннуров Рәзил, Хәйруллин Булат, Сафиуллин Халил катнаштылар.

*Әлеге укучыларга бары тик уңышлар гына теләп калабыз!*

## Иң көчлеләр билгеле

**Ниһаять, олимпиадаларның район турында җиңүчеләр дә билгеле булды:** инглиз теле буенча Шарапова Ләйсән белән Шакурова Алсу, тормыш иминлеге нигезләре фәненнән Хәйруллин Булат, Сафиуллин Хәлил призлы урынга ия булса, рус теле буенча Әһлиуллин Аяз, биологиядән Вәгыйзова Ләйсән призлы урынга ия булдылар.

**Уңышларыгыз белән котлыйбыз!**

# Көлке хикмәте



*****

Укытучы:

– Ильяс, ни өчен синең дәресләреңне гел дә гел әтиең әзерли?

– Соң бит әнинең һич тә вакыты юк. Җитешә алмый!..

****

Әтисе малаен тирги. Малае ялкау, начар укый.

– Хөрәсән! Беләсең килсә, Наполеон синең яшеңдә иң беренче укучы булган класста. «Отлично»га гына укыган!

– И-и әти, – ди икән малае. – Беләсең килсә, Наполеон синең яшеңдә дәүләт башлыгы, Франция императоры булган!..



****

– Балалар, – ди укытучы апа. – Бүген без инша, ягъни сочинение язарбыз. Аның темасы: «Әгәр дә мин директор булсам...» Ягез, башладык!

Укучылар шатыр-шотыр эшкә керешәләр. Хыял диңгезенә чумалар. Тик берсе генә һич тә кымшанмыйча утыра, әледән-әле кемнедер көткәндәй, ишек ягына борылып карый.

– Ә син, Марат, нигә язмыйсың, соңга каласың ич, өлгерми калуың бар...

– Ә мин... Суфия апа, личный секретаршамны көтәм!..

## Результат анкетирования обучающихся по профилактике правонарушений

**Участвовали 32 ученика (8 – 11кл)**

**1. Сколько Вам лет?** <u>**13 - 18**</u>

**2. Нравится ли Вам обучение в Вашей школе ?**

а) да - **32**

б) нет - **0**

**3. Приходят ли в Вашу школу посторонние лица?**

а) да - **29**

б) нет- **3**

**4.Если да, то ими являются:**

а) бывшие одноклассники - **7**

б) граждане, ранее окончившие Вашу школу - **7**

в) незнакомые ровесники либо взрослые лица- **4**

г) родители других учащихся- **11**

**5. С какой целью приходят?**

а) пообщаться- **20**

б) к девушкам-

в) с целью вымогательства или сбора денег-

г) по служебным вопросам- **9**

**6. Имеются ли факты вымогательства или сбора денег в Вашей школе со стороны одноклассников учащихся старших классов или посторонних лиц?**

а) да - **0**

б) нет- **32**

Если есть, то можете их назвать по имени, фамилии, по кличке?

**7. Слышали ли Вы о подобных случаях?**

а) в вашей школе (лицее, колледже)- **0**

б) возле школы(возле лицея, возле колледжа)- **2**

в) в своем микрорайоне- **1**

г) в дворовом клубе- **0**

д) в развлекательных центрах- **0**

е) на улице- **4**

ж) не слышал- **25**

**8. Чем они мотивируют сбор денег?**

а) нужно помочь товарищу- **12**

б) внезапно возникшими у них проблемами- **1**

в) сбора на «общак» (для криминальных структур) - **1**

г) никак не объясняют - **5**

**13 учеников не ответили**

**9. Имеется ли в Вашей школе (лицее, колледже) «смотрящий» или «неформальный лидер»?**

а) да - **2**

б) нет 30

**10. Подвергались ли Вы сами вымогательству либо сбору денег (или других материальных средств) со стороны одноклассников (одногруппников), учащихся старших классов (групп) или посторонних лиц, приходящих Вашу школу (лицей, колледж)?**

а)да **0**

б) нет- **32**

Если да, то можете назвать Ваших обидчиков по имени, фамилии, по кличке?

**11. Имели ли место факты насилия в отношении учащихся в Вашей школе (лицее, коледже)?**

а)да **-0**

б) нет- **32**

**12. Знаете ли Вы о группировках криминальной направленности, которые вымогают деньги с учеников, для сбора денег якобы в «общак»?**

а)да **-4**

б) нет- **28**



## ИҢ— ИҢНӘРЕБЕЗ!

Әни, әнием,әнкәй! Кадерләп назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз,һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез. Халык ана хакын хаклауны Алла хакын хаклауга тиңли. Ана турындагы бер әйтемне искә алыйк: "Ананны. арка кочып, Мәккәгә алып барсаң да, бурычыңны үтәп җиткерә алмассың. Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да, хакын хаклап бетерә алмассың”. Гасырлар аша килеп ирешкән бу гыйбрәтле, канатлы фразаларны җаныбызга, аңыбызга сеңдерү зарур.

Синең өчен кайгыртучы әниең булуы нинди зур бәхет ул. Аны ярату гына җитми, аның кадерләрен белергә, сүзен тыңларга, яхшы укуың, үзеңне үрнәк тотуың, эшкә өйрәнеп үсүең белән ананы шатландырырга кирәк.

**Әни (Н.Дәүли)**

Менә син иртә белән йокыдан уяндың да күзләреңне ачтың. Бүлмә кояш нуры белән балкып тора. Өйдә тәмле аш исе аңкый. Синең өс-баш киемнәрең урындыкка пөхтәләп җыеп куелган. Сиңа рәхәт-рәхәт.

Син шул вакытта үзең дә сизмәстән «әни» дип эндәшәсең. Нигә? Чөнки хәзер бу иртәнге сәгатьтә синең йөрәгеңдә шатлык тыпырчына, һәм ул менә хәзер «әни» дигән сүз булып синең күкрәгеңнән очып чыкты да ананың күңеленә барып кунды. Ананың йөзе елмайды, күзләре энҗе ташлары кебек ялтырап китте. Нигә? Чөнки «әни» дигән сүз белән аңа бу иртәнге сәгать тагы да матуррак булып китте. Аның күңеле татлы хисләр белән тулды. Тормыш синең телең аркылы шулай үзенең иң бөек юлдашын, армас-талмас хезмәтчесен котлады.

Әни. Нинди зур сүз бу!

Кеше үз гомерендә шул сүзне ничәмә-ничә кабат әйтә икән? Әйткән саен, ул сүз яңадан-яңа мәгънә алып килә. Ана шул бер сүздән синең шатлыгыңны да, кайгыңны да, уйларыңны да белә. Алай гына түгел, ана бу сүз аша синең йөрәгеңне күрә. Әйе, күрә. Чөнки «әни» дигән сүз ул үзе йөрәктә туа. Ә йөрәктән чыккан сүз йөрәккә барып керә. Әни дип әйттеңме, син инде көчле дә, син инде бәхетле дә!

Әниләрнең балалар тәрбияләүдәге ролен күтәрү, әниләргә хөрмәт, ихтирам тәрбияләү максатыннан, кадерле әниләребезгә багышлап, 28 нче ноябрьдә **Әниләр көне** уздырдык. Балалар үзләренең матур җырларын, биюләрен әниләргә бүләк иттеләр. Бәйрәмгә барлык әниләр дә килгән иде. Балалары белән бергә дөнья мәшәкатьләрен беразга гына булса да онытып, рәхәтләнеп ял иттеләр, күңел ачтылар.




**Булышчы**
**(Р.Миңнуллин)**

Әниемә эш күп өйдә –
Мин шуңа да булышам.
Менә әле дә мин аңа
Чынаяклар юышам.

Булышам шул, юышам шул,
Мин бит инде булышчы.
Уф, арыдым ! һаман бетми !
Әнием , кил, булышчы !

**Иң матур әни**

Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет –
һәр баланың
Үз әние булуы!

Минем әни, һич бәхәссез,
Иң сөйкемле әни ул!
Әйткән сүзе,
Кылган эше –
һәммәбезгә туры юл.

**Әниләрне саклыйк!**

Әниемнең эше – иң изге эш,
Әниемнең сүзе – иң назлысы.
Әнием кулы – иң йомшагы,
Әниемнең йөзе – иң-иң яктысы!

Әниләргә назлы сүзләр җитми,
Җитми әле мактау, котлау да!
Ә бит әниләрне гел яратып,
Зурлау кирәк барыбызга да!



Хөрмәтле

Раилә Заһитовна !

Сезне алтын юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!




Ноябрь аенда туучы кадерле

укытучыларыбыз һәм

техник хезмәткәрләребез:

Таһирова Розалия Вәзир кызы,
Гомәрова Флүсә Фоат кызы,

Садретдинова Гөлназ Ринат кызы,
Хисматова Зәкирә Закирҗан кызы!

Сезгә гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын юллыйбыз. Якты ал таңнар, зәңгәр күкләр сезнең күңелегезне һәрчак яктыртсын, балкытып торсын. Таң җилләренең назлысы, җан тынычлыгы, чиксез бәхетләр, эшегездә зурдан-зур уңышлар, яхшы, күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә.

Ноябрь аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:

Григорьев Антон, Шайдуллова Сиринә, Гайнуллина Алия, Гайнуллин Эдурад, Садртдинова Рузилә, Таһирова Гайшә, Фәйзетдинова Алсу!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хайбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Юнусова Виктория, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.